**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«19» октябрь 2021 ел** **№ 264**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарлары үз көчләрен югалтуын тану турында

«2017-2021 елларга Азнакай муниципаль районында янгын куркынычсызлыгы» программасын кабатлауны бетерү максатыннан, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 апрелендәге 138 номерлы «2020-2023 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгы һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү» карарынраслауга бәйле рәвештә, карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

2016 елның 30 ноябрендәге 346 нчы номерлы "2017-2019 елларга Азнакай муниципаль районында янгын куркынычсызлыгы" муниципаль программасы турында»;

- Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 декабрендәге карары белән расланган, 2019 елның 21 мартындагы 65 номерлы «2017-2019 елларга Азнакай муниципаль районында янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында»;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 23 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов